**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР**
**2018 елның 29 октябере**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 258**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 11 июлендәге 227 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 25.06.2013 № 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2018 елның 11 июлендәге 227 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 пунктның 1 бүлегенең «в» пунктчасында «биш» сүзен «дүрт» сүзенә алмаштырырга;

2) 12 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) хәрби исәпкә алу документлары - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;»;

3) 12 пунктның 9 пунктчасында «медицина учреждениесенең» сүзләрен «медицина оешмасының» сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында һәм

Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Совет председателе,
Район башлыгы Р.Г. Кәлимуллин